КАРАР (РЕШЕНИЕ)
Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы
Иске Икшермә авыл җирлеге составына керүче
Өч Нарат торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

12.11.2024 №1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 29 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» карарына таянып 2024 нче елның 12 ноябрендә узган гражданнар җыенында «2025 нче елда Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге Өч Нарат торак пунктында балигъ булган, Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге составына керүче Өч Нарат торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә тезелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

– Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Өч Нарат торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын ремонтлау).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә буенча:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 73 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 44 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

- «Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучыларның 44 е тавыш бирде;
- «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 е тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге составына керүче Өч Нарат торак пунктында гражданнар җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип танырга.

2. «2025 нче елда Саба муниципаль районының Иске Икшермә авыл җирлеге составына керүче Өч Нарат торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм аны түбәндәге максатларда файдаланырга ризамы:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Өч Нарат торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын ремонтлау)» - дигән сорауны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Иске

Икшермә авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/ikshurma адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Җыенда рәислек итүче:
Иске Икшермә авыл җирлеге башлыгы А.И.Биккинин